РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, Кукмара ш., Ленин ур., 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ КАРАР

22 апрель, 2024 ел № 8

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советының 2017 елның 31 октябрендәге 22 номерлы карарына каршы Татарстан Транспорт прокуратурасының 2024 елның 2 февралендәге 23/1-12 номерлы протесты белән бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясының 3 өлеше нигезендә, шулай ук «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Федераль законның 23 статьясына таянып, Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Кукмара шәһәре Советының 2017 елның 31 октябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә (2018 елның 05 июнендәге 11 номерлы; 2019 елның 07 августындагы 13 номерлы; 2020 елның 12 мартындагы 7 номерлы, 2022 елның 18 ноябрендәге 24 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10.1 пунктын – «Торак пункт территориясендә, читләшү полосасы чикләрендә уза торган тимер юл юллары, юллар ашачыгу юллары һәм җәяүлеләр кичүләре әлеге корылмаларны эксплуатацияләүче оешмалар көче белән карап тотыла» – төшереп калдырырга;

1.2. 35.11 пунктында «тимер юлларны» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 37 пунктның 5 пунктчасында «һәм тимер юл» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 65пунктта («тимер юл») сүзен төшереп калдырырга;

1.6. 66 пунктта («тимер юл») сүзен төшереп калдырырга;

1.6. 67 пунктта («тимер юл») сүзен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев